ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.04.2020 г. Заинск № 194

**Ташламалы транспорт картасы
һәм балалар ташламалы транспорт
картасы буенча гражданнарга
транспорт хезмәтләре күрсәтүгә
бәйле рәвештә транспорт оешмаларына
Зәй муниципаль районы бюджетыннан
субсидия бирү тәртибен раслау турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләр бирүдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга – товарлар җитештерү, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләр белән шөгыльләнүчеләргә - субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында" 2016 елның 06 сентябрендәге 887 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Ташламалы транспорт картасы һәм балалар ташламалы транспорт картасы буенча гражданнарга транспорт хезмәтләре күрсәтүгә бәйле рәвештә транспорт оешмаларына Зәй муниципаль районы бюджетыннан субсидия (алга таба – субсидия) бирү тәртибен 1нче кушымта нигезендә расларга.

2. Зәй муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү буенча комиссия составын 2нче кушымта нигезендә расларга.

3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетын Зәй муниципаль районы бюджетыннан субсидия бирү буенча вәкаләтле орган итеп билгеләргә.

4.Әлеге карарны Зәй муниципаль районы рәсми сайтында (http://zainsk.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Н.А. Нифатовка йөкләргә.

**Башкарма**
**комитет җитәкчесе** **И.Ф. Хафизов**

П.Д. Емельянов
3 07 19

Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
«30» 04 2020 ел
194 номерлы карарына
1нче кушымта

**Ташламалы транспорт картасы һәм балалар ташламалы транспорт картасы буенча гражданнарга транспорт хезмәтләре күрсәтүгә бәйле рәвештә транспорт оешмаларына Зәй муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләр бирүдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга – товарлар җитештерү, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүләр белән шөгыльләнүчеләргә - субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында" 2016 елның 06 сентябрендәге 887 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставы нигезендә эшләнде.

1.2. Әлеге тәртип ташламалы транспорт картасы һәм балалар ташламалы транспорт картасы (алга таба - субсидияләр) буенча гражданнарга транспорт хезмәтләрен күрсәтүгә бәйле рәвештә Зәй муниципаль районы бюджетыннан транспорт оешмаларына субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү процедурасын билгели.

1.3. Субсидияләр агымдагы финанс елына вәкаләтле орган - Зәй муниципаль районы Башкарма комитетына (алга таба - вәкаләтле орган) каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

1.4. Агымдагы финанс елына Зәй муниципаль районы бюджетында каралган субсидияләр Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының территориаль бүлегендә ачылган вәкаләтле орган исәбендә исәпкә алына.

## 2. Субсидияне бирү шартлары һәм тәртибе

2.1. Юридик затлар (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш), шәхси эшмәкәрләргә – товар җитештерүчеләр, эшләр башкаручылар, хезмәт күрсәтүчеләргә субсидияләр бирү турында килешү төзү өчен дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында Россия

Федерациясе законнары нигезендә үткәрелгән башкаручыны билгеләү нәтиҗәләре буенча төзелгән Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүгә бәйле хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контракт нигез булып тора.

2.2. «Социаль карта» АҖ шәһәр һәм шәһәр яны пассажир транспортында йөрү өчен түләүнең автоматлаштырылган системасы операторы тарафыннан тапшырылган хисап аенда ташламалы транспорт карталарын тулыландырудан акчаларны бүлү хисаплары нигезендә, вәкаләтле орган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 23 июлендәге 1416-р номерлы билгеләмәсе буенча белешмә-исәп һәм хисап әзерли, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә аерым категориядәге гражданнар өчен җәмәгать транспортыннан бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 19 декабрендәге 123-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясы нигезендә субсидияләр бирү турында комиссия беркетмәсен раслый, документларны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына җибәрә.

2.3. Исәп-хисап счетына акчалар керүгә карап, вәкаләтле орган акчаларны транспорт оешмасының «Ак Барс» Банкта ачылган исәп-хисап счетына 10 эш көне эчендә күчерә.

2.4. Субсидия бирүдән баш тарту турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

- транспорт оешмасының әлеге тәртиптә бәян ителгән критерийларга туры килмәве;

- әлеге нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга бюджет йөкләмәләре лимитлары булмау.

2.5. Транспорт оешмасына тиешле субсидия күләме «Татарстан Республикасында айлык бердәм социаль юл билетын һәм айлык бердәм балалар социаль юл билетын бирү тәртибен раслау турында» 2005 елның 07 апрелендәге 161 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган бердәм айлык социаль юл билеты һәм айлык бердәм балалар социаль юл билеты буенча гражданнарга транспорт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә муниципаль районда (шәһәр округында) транспорт оешмаларына чыгымнары күләмен исәпләү методикасы нигезендә исәпләнә.

Ктр.орг. = ((SUM (Тiгор х Пi) + SUM (Тiпр х Рiпр)) - Втр.орг., монда:

Ктр.орг. - муниципаль районда (шәһәр округында) юл йөрү билеты һәм балалар өчен юл йөрү билеты буенча гражданнарга транспорт хезмәтләре

күрсәтүгә бәйле рәвештә транспорт оешмасы чыгымнарын Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсацияләү күләме;

i - транспорт оешмасында транспорт төре (автобус);

Тiгор - Зәй муниципаль районында i-транспорт төре буенча закон нигезендә шәһәрдә пассажирлар йөртүгә гамәлдәге тариф;

Пi - хисап аенда автоматлаштырылган юл йөрү өчен түләү системасы операторы (алга таба - АСОП) мәгълүматлары буенча транзакцияләрнең факттагы саны;

Тiпр - Зәй муниципаль районында i-транспорт төре буенча закон нигезендә шәһәр янында йөри торган транспортта пассажирлар йөртүгә гамәлдәге тариф;

Рiпр - АСОП операторы мәгълүматлары буенча, шәһәр яны транспортында йөртелгән пассажирлар- үтелгән километрлар саны;

Втр.орг.-АСОП операторы мәгълүматлары буенча хисап аена транспорт оешмасының тулыландырылган ташламалы транспорт карталарыннан табышы.

## 3. Субсидия алу хокукына ия юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр категорияләре

Субсидияләр субсидия бирү турында карар кабул итү планлаштырылган айдан соң килә торган айның беренче числосына түбәндәге критерийларга туры килә торган транспорт оешмаларына бирелә:

- транспорт оешмасы Зәй муниципаль районында гомуми файдаланудагы транспортта пассажирлар йөртү эшчәнлеген гамәлгә ашыра һәм кешеләр йөртүне гамәлгә ашыру өчен матди-техник чараларга ия;

- транспорт оешмасының Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турында законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият взнослары, пенялар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаска тиеш;

- транспорт оешмасының Зәй муниципаль районы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән, һәм Зәй муниципаль районы бюджеты алдында срогы чыккан башка бурычлары булырга тиеш түгел;

- субсидия алучы - юридик затлар үзгәртеп кору, бетерү процессында булырга тиеш түгел, аларга карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, субсидия алучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган булырга тиеш, ә субсидия алучы - шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген шәхси эшмәкәр буларак туктатырга тиеш түгел (әгәр мондый таләп хокукый акт белән каралган булса);

- транспорт оешмалары чит ил юридик затлары булырга тиеш түгел, шулай ук салым салуның ташламалы салым режимы һәм (яисә) мондый юридик затка карата финанс операцияләре (офшор зоналары) уздырганда мәгълүматны ачуны һәм тапшыруны күз алдында тотмаучы, теркәлү урыны Россия Федерациясе

Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән дәүләт яисә территория булып торган, устав (җыелма) капиталында чит ил юридик затларының катнашу өлеше тулаем алганда 50 проценттан артып киткән Россия юридик затлары субсидия алучы була алмый;

- транспорт оешмасы әлеге тәртипнең 1 бүлегендә күрсәтелгән максатларга башка норматив хокукый актлар яисә муниципаль хокукый актлар нигезендә Зәй муниципаль районы бюджетыннан акча алмаска тиеш.

### 4. Субсидиядән максатчан файдалануны контрольдә тоту

4.1. Вәкаләтле орган һәм муниципаль финанс контроле органы оешмалар тарафыннан субсидияләрдән файдалану шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

4.2. Субсидия бирү шартлары бозылган яисә ул максатчан файдаланылмаган очракта, вәкаләтле органның язмача таләбе буенча субсидия алучы тарафыннан, Зәй муниципаль районы бюджетына кире кайту турында таләп алынган көннән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, субсидия кайтарылырга тиеш. Субсидия билгеләнгән срокта кире кайтарылмаган очракта, ул Зәй муниципаль районы бюджетына гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
эшләр идарәчесе Т.А. Лоптова

Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
«____» ________2020 ел
____ номерлы карарына
2нче кушымта

Ташламалы транспорт картасы һәм балалар ташламалы транспорт картасы буенча гражданнарга транспорт хезмәтләре күрсәтүгә бәйле рәвештә транспорт оешмаларына Зәй муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү буенча комиссия составы

| | | |
|---|---|---|
| Нифатов Н.А. | - | Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары, комиссия рәисе; |
| Байрашев П.А. | - | финанс-бюджет палатасы рәисе (килешү буенча) |
| Архипова Р.М. | - | Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге башлыгы; |
| Городнова О.В. | - | Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм исәп-хисап бүлеге башлыгы; |
| Исаичев М.Е. | - | ТКХ, төзелеш, транспорт, энергетика, элемтә һәм юл хуҗалыгы бүлеге башлыгы. |

Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
эшләр идарәчесе Т.А. Лоптова